КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОШТОРМА-ЮМЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

20 февраль 2019 ел №3

Кукмара муниципаль район Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче мартында 8 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 30нчы октябрендәге 387- ФЗ номерлы “Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 2нче һәм 28нче матдәләренә үзгәрешләр кертү хакындагы” Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Кукмара муниципаль район Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014нче елның 14нче мартында 8 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында “хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләрен “комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: А.Н. Рамазанов